| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«МУКМИН-КАРАТАЙСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«МӨЭМИН-КАРАТАЙ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

**2023 елның 18 декабреннән** **№48**

«Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 03 октябрендәге 34 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Мөэмин-Каратай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. « Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2016 елның 03 октябрендәге 34 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Мөэмин-Каратай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.6 пунктының икенче абзацында икенче җөмләне төшереп калдырырга;

4.10 пункт гамәлдән чыккан дип танырга;

4.13 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«4.13. Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турындагы карар, әлеге Нигезләмәнең 4.7 пунктының 2 абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш, сыйныф чинын барлык кирәкле документлар белән җирле үзидарәнең органына яисә вазыйфаи затына бирү турында тапшыру кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Мөэмин-Каратай авылында урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск муниципаль районы
«Мөэмин-Каратай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе Ә.А.Ханнанова